СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Иске Чүриле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**26.01.2016 ел** **№ 12**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2016 елның 22 гыйнварындагы 11 номерлы Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 13 мартына Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«2016 елда Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертү (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлар тыш, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен) һәм акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин | - Иске Чүриле, Венета авыллары өчен мотопомпалар сатып алу; | 20 000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | итү | - Иске Чүриледә янгын гидранты урнаштыру | 10 000 |
| 2 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | юлларны ремонтлау (вак таш)<br>Иске Чүриле авылы<br>Ашабаш авылы<br>Михайловка п. | <br>60 000<br>20 000<br>100 000 |
| 3 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | Штерә авылында чишмә территориясен төзекләндерү | 10 000 |
| | | Барлыгы: | 220 000 |

Экономияләнгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Иске Чүриле авылы, Яңа ур., 52; Штерә авылы, Совет ур., 30; Ашабаш авылы, Комсомол ур, 4а; Венета авылы, Үзәк ур., 13.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Заһидуллина

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СТАРОЧУРИЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ОГРН 1121690091879 ИНН 1609012646 СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ